Республика Татарстан СОВЕТ

ЯНУРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЯНУРЫС
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423370, Татарстан Республикасы, Сарман районы, Янурыс авылы,
Ленин ур., 43 а, тел.4-10-19 ИНН 1636001403 КПП 163601001 Р/С
40204810500000570023 ОГРН 1031604000757 ОКАТО 92253884000

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 гыйнвар 2016 ел №1

**Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актларының регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга сала торган законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 43.1 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ЗР номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы башлыгы белән төзелгән 2016 елның 21 гыйнварындагы Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җибәрү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә карар бирәм:

I. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җибәрү эше барышында Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актлар җыю һәм җибәрү буенча үзара хезмәттәшлеге регламентына һәм алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль районы башлыгының 2016 елның 20 гыйнварындагы 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен кулланырга;

муниципаль район Советына юллама өчен җаваплы затларны һәм алар турында регистрга кертелергә тиешле белешмәләрне билгеләргә:

регистрны оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга салучы законнарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка чаралар күрергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасының «Сарман муниципаль _ районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сарман муниципаль районының
Янурыс авыл җирлеге башлыгы А. А. Мөхәммәдиева